# КАРАР

2022 елның 19 ноябре, № 1

## Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Ятмас-Дусай авыл җирлеге Шепшеңәр авылында узара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында " 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2022 елның 14 ноябрендә, 2022 елның 19 ноябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча узган гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

"Сез яшәү урыны буенча Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Ятмас-Дусай авыл җирлеге Шепшеңәр авылы территориясендә теркәлгән , балигъ булган һәр яшәүчедән, укучылар һәм көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан (курсантлар); I төркем инвалидлардан; 85 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 2023 елда үзара салымны 5000 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

- Шепшеңәр авылында су башнясын карап тоту һәм ремонтлау (проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру);

- зиратны карап тоту һәм ремонтлау, зират өчен койма (хуҗалык инвентаре, ремонт өчен җиһазлар һәм материаллар сатып алу), проект - смета документациясен эшләү;

- Шепшеңәр авылында Мәктәп урамындагы, Урман урамындагы вак таш җәеп юлларны ремонтлау, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;

- Шепшеңәр авылы юлларын кардан чистарту (проект-смета документациясен эшләү, килешү буенча түләү);

-граниттан язулы мемориальakталар сатып алу һәм урнаштыру (проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру);

-чишмәне ремонтлау, карап тору һәм төзекләндерү (проект-смета документлары, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру);

- Шепшеңәр авылында шлагбаум урнаштыру (проект-смета документациясен эшләү техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру);"

« РИЗА» "КАРШЫ"

Гражданнар җыенының йомгаклау беркетмәсе нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 90 кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 48 кеше.
Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар түбәндәгечә бүленде:
"Әйе» дип гражданнар җыенында катнашучы 48 кеше тавыш бирде;
«юк» дип гражданнар җыенында катнашучы 0 кеше тавыш бирде.
Югарыда бәян ителгәннәрдән чыгып, гражданнар җыены карар бирде:

1.Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Ятмас-Дусай авыл җирлеге Шепшеңәр авылында узган гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләре – кабул ителгән дип танырга.

2. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Ятмас-Дусай авыл җирлегенең Шепшеңәр авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән,укучылар һәм көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан (курсантлар); I төркем инвалидлардан; 85 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 2023 елда үзара салымны 5000 сум күләмендә кертүне һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүне расларга карар иттек:

- Шепшенар авылында су башнясын карап тоту һәм ремонтлау (проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру);

- зиратны карап тоту һәм ремонтлау, зират өчен койма (хуҗалык инвентаре, ремонт өчен җиһазлар һәм материаллар сатып алу), проект - смета документациясен эшләү;

- Шепшенар авылында Мәктәп урамындагы, Урман урамындагы вак таш җәеп юлларны ремонтлау, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;

- Шепшенар авылы юлларын кардан чистарту (проект-смета документациясен эшләү, килешү буенча түләү);

-гранитттан язулы мемориаль такталар сатып алу һәм урнаштыру (проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру);

-чишмәне ремонтлау, карап тору һәм төзекләндерү (проект-смета документлары, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру);

- Шепшенар авылында шлагбаум урнаштыру (проект-смета документациясен эшләү техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру);”

Карар кабул ителгән дип расларга.

3. Җыенның нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Ятмас -Дусай авыл җирлеге башлыгы Ф.Х.гарифуллина